Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№ 1 (131)

19 февраль 2015 ел



Влад Михневский фотосы

Күп телләрне белү – яхшы шөгыль, туган телең үги калмаса.
Җанын салып әйткән әткәң сүзен синең аша балаң аңласа.
*(Равил Фәйзуллин)*

# Телләр белгән – илләр гизгән

Галимнәр сүзенә ышансак, җир шарында 2500дән 5000гә кадәр кулланылышта йөргән тел бар. Шуларның берсе – үзебезнең татар теле! Ана теле... Шул ук галимнәрнең сүзенә караганда, һәр ике атна саен бер тел үле телләр исемлегенә керә икән. Татар теленә дә куркыныч янавы сер түгел. Дәүләт, җитәкчелек, университет тарафыннан төрле проектлар оештырылар, әйе. Ләкин ана теле аналардан, балалардан башлануын онытмасак икән. Бу – безнең, сезнең уртак эшебез, уртак бурычыбыз. Югарыдагы фотода тел мәсьәләсен төрле яклап чишәргә тырышкан студентларыбыз. Алар турында 2нче биттә тулырак мәгълүмат таба аласыз.

## • Вакыйгалар эзеннән

### КӨНЧЫГЫШКА ТАБА ЮЛ АЛЫП

Япония белән кызыксынучылар, япон телен өйрәнүче студентлар, галимнәр өчен яңа мөмкинлекләр ачыла. **16 нчы февраль** көнне Япониянең **Цукуба шәһәре университеты белән яңа килешү имзаланды.** Аның нигезендә, ике университет үзара галимнәр һәм студентлар алмашу программаларын ачып җибәрә. КФУ ректоры Илшат Гафуров тагын берничә шәһәрдә килешү имзалаячагын хәбәр итте.

• • • •

### ЯШЬ ГАЛИМНӘР «ФАБРИКАСЫ»

**13 нче февраль** көнне «УНИКС»ның Кече залында **КФУның яшь галимнәр ассоциациясенең җыелышы узды.** Чара барышында әлеге ассоциациянең эшчәнлеген яктырткан доклад белән КФУ ректоры **И.Гафуров,** фәнни эшчәнлек буенча проректор **Д.Нургалиев**, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының фәнни эшчәнлек буенча директор урынбасары **В.Туманин** чыгыш ясады. Яшь галимнәр ассоциациясенең советына яңа мөдир итеп А. М. Бутлеров исемендәге Химия институтының физик химия кафедрасы доценты **Михаил Варфоломеевны** куйдылар. Шулай ук яңа әгъзалар да сайланды.

Исегезгә төшереп узабыз: әлеге ассоциациягә 1996 нчы елда нигез салына. Тора-бара ул шәһәркүләм масштабта эшләп алып бара башлый. Бүгенге көндә исә университетыбыз дәрәҗәсен Россия күләмендә таныткан һәм күтәргән оешмалардан исәпләнә.

• • • •

### ЯҢАДАН ЯҢА ЕЛ!

Университетыбызда **15 нче февральдә тагын бер тапкыр яңа ел уздырылды**. Бу юлы кытайлылар календаре буенча яз һәм яңа ел килүен, ягъни **chun jie** бәйрәмен билгеләп уздылар.

«УНИКС»ка килеп керү белән, тылсымлы сыннар, кытай уеннары, сәнгать үрнәкләре дөньясына чумасың – чарага килүчеләр арасында бу күренешкә сокланмаган кеше калмагандыр. Чара холлдан Зур актлар залына күчте. Биредә В.А.Летяев, Д.Г.Зәйнуллин, Ли Мяо, И.Р.Усманова һәм башка мәртәбәле кунаклар катнашты. Чараны Казан шәһәренең 13 нче номерлы мәктәбеннән килгән хор тәмамлады. Алар кытай телендә ике җыр башкарды. Сүзләре безгә – гади тамашачыга аңлашылып бетмәде, ләкин аһәңе моңым түгел. Нәрсә генә дисәгез дә, көй, моң, җыр кешеләрне берләштерә!

• • • •

### ДИН МӘКТӘБЕ ИШЕКЛӘРЕН АЧТЫ

**25 нче май – 4 нче июнь арасында Казанда Санкт-Петербург шәһәренең Аурора Университеты һәм ТАИФ Профессурасы ярдәме белән «Россиядә ислам» дип аталган җәйге мәктәп узачак.** Аның максаты – дин өлкәсендә галим-теоретиклар һәм төбәгебездә исламны үстерәчәк практиклар әзерләү.

Биредә ислам диненең нечкәлекләрен белгән галимнәр студентларга киләчәк фәнни эшләренең темасын табарга, консультацияләр уздырып, ислам белән бәйле сорауларга җавап бирергә тырышачак.

Катнашырга теләгегез булса, университет сайтына кереп, тәгәрәк мәгълүмат ала аласыз. Ашыгыгыз, гаризалар 30 нчы апрельгә кадәр генә кабул ителә.

• • • •

### ТАРИХКА СӘЯХӘТ ИТҮЧЕЛӘР

**Казан университетының 210 еллык юбилеена багышланган викторина нәтиҗәләре билгеле булды!** 6 нчы февраль көнне матбугат хезмәте һәм мәгълүмат Депратаменты җитәкчесе Ләйлә Мөхтәрова һәм музей директоры Стелла Писарева җиңүчеләрне котлады, истәлекле бүләкләр тапшырды. Беренче урынны – 2 нче курс студенты **Лилия Хәйретдинова**, икенче урынны – 4 нче курс студенты **Айсылу Гәрәева**, өченче урынны исә 1 нче курс студенты **Чулпан Вәлиева** яулады. Иң кызыгы шул: җиңүчеләр арасында бер генә тарихчы да, бер генә филолог та юк. Беренче өчлеккә биолог, психолог һәм химик керде. Катнашучыларның сүзләренә караганда, әлеге чара аларга кабат үткәнгә күз салырга, тарихны айкап чыгарга этәргеч булган.

Сез утырган өстәл артында, бәлки, кайчандыр сезнең бабагыз яки сезне илһамландырган галим үзе утыргандыр. Бу хакта уйлап караганыгыз булмадымы?

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

---

## • Чара

# Галимнәр йолдызлыгы

Университет шундый дөнья инде ул, биредә һәр мөгаллим – шәхес, һәр галим – тарихка кереп калачак исем. Алар – бу дөньяга белем һәм яктылык алып килүчеләр. Язган сүзләре, ачкан йолдызлары гыйлем күген озын-озак яктыртып тора. 12 нче февраль көнне Казан университетының Тарих музее Актлар залында шундый тарихи шәхесләрнең берсе – Хәбибуллин Шәүкәт Таип улының 100 еллык юбилее булып узды.



Сулдан уңга: Максим Глушков һәм Альберт Аганов.

Шәүкәт Хәбибуллин – чорыбызның иң атаклы астроном галимнәреннән, Бөек Ватан сугышы ветераны, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, дистәләрчә галимнәргә мөгаллим булган шәхес!



Алгы планда Илһим Галиуллин.

Казан университеты диварларында аны искә алып, юбилеен билгеләп үтү – рәсми чара гына булудан туктап, якты истәлекләргә тулы, җылы бер кичәгә әверелде. Чарада Ш.Хәбибуллинның хезмәттәшләре һәм укучылары, аның канаты астында университетыбыз галимнәренә әверелгән шәхесләр, шулай ук бүгенге көндә Физика институтының фәнни тормышында актив катнашучы студентлар һәм аспирантлар да чыгыш ясады. Президиумга КФУ ректоры **Илшат Гафуров**, Физика институты директоры **Альберт Аганов** һәм ТР Фәннәр Академиясе академигы **Наил Сәхибуллин** чакырылган иде.

Илшат Рәфкать улы сәләтле астроном-студентлар өчен – Ш.Т.Хәбибуллин исемендәге махсус стипендия, ә астрономия белән кызыксынучы югары сыйныф укучылары өчен шул ук исемдәге бәйге булдырырга тәкъдим итте. Ректорыбыз үз чыгышында Шәүкәт Таип улы башлаган эшләрнең мөһимлеген ассызыклады. Физика институты директоры А.Аганов АКШта Гарвард университеты тарафыннан студентлар һәм аспирантлар өчен оештырыла торган Халыкара фәнни бәйгедә уңышлы чыгыш ясаган **Илһам Галиуллинны** һәм «Космос физикасы» дип исемләнгән студентлар фәнни конференциясендә III дәрәҗәле дипломга ия булган **Максим Глушковны** котлады.

Н.Сәхибуллин Шәүкәт Таип улының тормыш юлы һәм фәнни-гамәли эшчәнлеге белән таныштырды.

Әлеге чарадан соң илһамланмый булмый торгандыр. Күккә, тирә-юнегә тагын бер тапкыр башка күзлектән карарга мәҗбүр итә торган чара иде бу. Уйлап карасаң, югары уку йортыбыз – гыйлем күгендәге иң якты исемнәрне туплаган йолдызлык кебек. Янәшәңдә, синең яныңда тарихны үзгәртә алырлык бөек галимнәр яши ләбаса. Менә син алар белән исәнләшеп узасың, бер үк университет ишеген ачып керәсең, бер үк лифтта күтәреләсең, ә кайчакта бер үк өстәл артында утырасың! Шуны да онытмаска икән: үзебезнең ике гасырлык тарихы булган университетыбыз диварларында киләчәкнең галимнәре үсә. Бәлки, сез дә шуларның берседер?

**В.Михневский һәм И.Басырова фотолары**

---

## • Сәяхәттән кайткач

Соңгы елларда Төркия Җөмһүриятенең Мәвлана программасы югары уку йорты студентларын һәм укытучыларын үзара алмашу буенча берничә юнәлеш ачты. Төрле илләрдән килгән студентлар, укытучылар бер семестр, өч ай яки 15 көн дәвамында, Төркиянең үзләре сайлаган университетларында белем эсти, тел өйрәнә, тәҗрибәләре белән уртаклаша алалар.

# Төркиядә татар татарны таба



Мәвланага һәйкәл, Измир шәһәре, Төркия.

**Альбина ВӘЛИЕВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студенты

Студентлар – бер урында гына утыра торган халык түгел: кайда нинди мөмкинчелек бар – кулланып калырга ашыгалар. 2014/2015 нче уку елының беренче семестрында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең дүрт студенты шундый бәхеткә иреште. Өченче курс студентлары **Альбина** һәм **Назлыгөл Вәлиевалар** – Искешәһәрнең Анадолу, бишенче курс студенты **Рөстәм Шәмсетдинов** – Анкараның Гази, ә дүртенче курс студенты **Айгөл Салихова** Анкараның «Йылдырым-Бәязит» университетларында укып кайттылар..

Бер семестр дәвамында студентлар төрле факультетларда, төрек һәм инглиз телләрен тирәнтен өйрәнеп, конференцияләрдә катнашкан, лекцияләр тыңлаган, студентлар белән аралашкан. Университетта оештырылган төрек теле курслары да безнең студентлар өчен бик файдалы булган: нәрсә дисәң дә, чит илгә чыкканда, әзерлексез чыгу мөмкин түгел. Университетыбызда үзләштерелгән дәресләр, яхшы нигез булып, чит мохиттә югалып калмаска ярдәм иткән.

Студентларыбыз сүзенә караганда, Төркия университетларының уку-укыту системасы аларга ошаган. Укучы гел тонуста булсын өчен, укыту программасыннан чыгып, һәр ай ахырында бөтен фәннәрдән имтиханнар үткәрелә. Нәтиҗәләр исә семестр азагындагы имтиханга кочле тәэсир ясый. Шуның өчен студентлар, һәр чарага житди якын килеп, уку башланган көннән имтиханга әзерләнү эшенә керешәләр.

Төркия университетларында да уку бинаралы бик матур һәм зәвыклы итеп, яңа технологияләрне исәпкә алып төзелгәннәр. Ләкин тарихи нигезләр дә аз түгел... Алар, бихисап зур мәйданнарны алып, тирә-юньгә илаһи гүзәллек бирепп тора, дип уртаклашты Альбина Вәлиева. Мәсәлән, Анадолу университетының үз концерт залы, спорт залы, китапханәсе, ашханәсе, хастаханәсе, кинотеатры, музее, хәтта аэропорты да бар. Студентның тормышы кызык һәм файдалы үтсен өчен, барлык шартлар да тудырылган.

Оештыручылар бер генә көнне дә буш калдырмаган, программа буенча укучы студентлар өчен ял көннәрендә дә төрле экскурсия турлары оештырган. Шушы ярты ел дәвамында безнең студентлар Төркиянең данлыклы шәһәрләренә сәяхәт иткәннәр: юллары Каппадокия, Истамбул, Анталья кебек шәһәрләргә илткән.

Ә бу исә, үз чиратында, анда яшәүче халыкның тормышкөнкүреше, гореф-гадәтләре, традицияләре хакында бик күп мәгълүмат тупларга менә дигән мөмкинлек.

Татар, кая гына барса да, милләттәшен эзли, моңсыз факт. Безнекеләр дә Төркиядә яшәүче милләттәшләребез белән даими күрешеп, аралашып торганнар. Димәк, төрекләр тормышы гына түгел, татарларның көнкүреше белән дә танышырга өлгергән студентларыбыз!

Төркия сезне дә кызыксындырдымы? Алайса, әлеге программада катнашырга ашыгыгыз! Тырышкан табар, ташка кадак кагар, диләр бит...

Очрашу

# Татар матбугаты үсешен барлап...

Президент карары белән 2015 нче ел Россиядә Әдәбият елы дип игълан ителде. Татарстанлылар өчен исә 2015 нче ел тагын бер мөһим вакыйга белән истәлекле: быел татар матбугатына 110 яшь тула.



✦ Сулдан уңга: М. Сәфәров, В. Гарифуллин, Р. Ратникова

**Айгөл АБДРАХМАНОВА**

Нәкъ менә XX йөздә Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан кебек бөек шәхесләребез татар телендә нәшер ителгән газета-журнал тарихын башлап җибәрә. Ә йөз елдан соң да татар матбугатын үстерү эшләре дәвам итәме, дигән соравыгыз туса, димәк, сез Казан (Идел буе) федераль университеты, ТР матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы, ТР Журналистлар берлеге тарафыннан уздырылган «Татар телендәге мәгълүмати мохит: хәзерге хәле һәм үсеш юллары» конференциясендә катнашмагансыз. Татар журналистикасының кичәгесе, бүгене, иртәгәсе турында кайнар бәхәсләр, фикер алышулар – барысы да яңа дәрәҗәгә күтәрелүне, татар матбугатын үстерү эшенең дәвамлы булуын күрсәтә торган факторлар!

Фәнни-гамәли конференция Журналистлар берлеге бинасында һәм Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникацияләр институтында 11-12 нче февраль көннәрендә уздырылды.

Чараны ачып җибәрү өчен сүз ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе **Римма Атлас кызы Ратниковага** бирелде. Ул исә, үз чиратында, татар матбугатының бүгенге проблемаларына зур игътибар күрсәтергә һәм аларны хәл итү эшләрен даими алып барырга кирәклеген ассызыклады. Чыгыштан аңлашылганча, 2020 нче елга кадәр Республикабыздагы барлык мәгълүмати чараларны да тигез дәрәҗәдә татар һәм рус телләрендә алып баруга күчү беренчел максат итеп куела.

«Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире **М.Сәфәров** бүгенге көндә татар матбугаты өчен чит дип саналган «сары пресса» темасына тукталып узды, аның классик газета-журналларга тәэсире һәм мөмкин булган әхлакый зыяны турында да сүз алып барды. «XX гасыр башында чыккан матбугат – безгә бүген дә үрнәк. Сыйфатлы, профессиональ журналистика белән гаилә бизнесын бутарга ярамый!» – диде Минназыйм ага, һәм аның сүзләре залны шактый дулкынландырды, чөнки бу сүзләр үзебезгә кагыла бит! Әлеге мәсьәләне урап узарга ярамый, сыйфатсызлык нәтиҗәсендә «югалган» һәр басма – артка чигенү. Бигрәк тә бүгенге вәзгыятьтә!



Ерак араны якын итеп килгән «Шәһри Чаллы» газетасының баш мөхәррире Илсур Флүс улы Тимеров та үз борчулары, фикерләре белән бүлеште. Алдагы 2 ел эчендә шәһәр газетасының тиражын 20000гә кадәр арттыруны максат итеп куйган әлеге басма. Без исә ике елдан соң алар тарафыннан башлап җибәрелгән әлеге технологиянең практик уңышларын күрергә өметләнәбез. «Шәһри Чаллы»ның Гали Акыш исемендәге 84 нче номерлы лицей-интернат белән тыгыз элемтәдә булуын да билгеләделәр. Ләкин әлеге уку йортыннан чыккан балалар татар матбугаты үсешенә үз өлешләрен кертергә теләрләрме? Тиражның артуын алардан гына көтеп калу дөресме? Әлеге алым проблеманың вакытлыча чишелеше генә түгелме икән? Сорау ачык кала.

Пленар утырыш вакытында, «Алтын каләм» Республикакүләм балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр фестивале дә бары уңай яктан гына искә алынды. Моңа чаклы район күләмендә генә уздырылган «Нургаян фестивале»н территориаль яктан үстерү турында да сүз алып барылды.

Пленар утырыш шуның белән тәмамланды. Актуаль мәсьәләләрне үз эченә алган әлеге фәнни-гамәли конференция үз эшчәнлеген «Татар матбугаты тарихы», «Татар матбугат кырында яңа технологияләр үсеше», «Татар журналистлары мирасын барлау мәсьәләләре» һ.б. секцияләрдә дәвам итте.

«Татар телендәге мәгълүмати мохит: хәзерге хәле һәм үсеш юллары» конференциясе, бөтен сорауларга да җавап тапмаса да, киләсе берничә ел өчен үсеш максатларын билгеләде.

**Р.Габдрахманова фотолары**

## Туган тел көне

**21 нче февраль – 1999 нчы елның 17 нче ноябрендә ЮНЕСКО тарафыннан Халыкара туган тел көне дип игълан ителгән. Нигә нәкъ 21 нче февраль диярсез? Ә җеп очы кулланучыларының саны буенча дөньяда алтынчы урынны алып торган бенгали теле тарихына барып тоташа.**

Һиндстан һәм Бангладешта 181 миллионга якын (кайбер чыганакларга караганда, 250 миллион) бенгал халкы яши. Ләкин аларның теле 1971 нче елда Бангладеш дәүләте (Көнчыгыш Пакъстан) төзелгәч кенә рәсмиләштерелә. Ул вакытка кадәр исә берничә күтәрелеш булып ала. Шуларның 1952 нче елдагысы 21 нче февральнең Халыкара туган тел көне булып китүенә сәбәпче: Бангладешның хәзерге башкаласы Дакка шәһәрендә үз туган телен яклап демонстрациягә чыккан берничә студент полиция тарафыннан үтерелә. Соңрак, 1999 нчы елда, аларны искә алу һәм туган телнең әһәмиятен ассызыкларга теләү максатыннан, 21 нче февраль Халыкара туган тел көне дип игълан ителә.

Мөхәррир сүзе

### *Хәерле сәгатьтә!*

*Динара Миннекаева белән без кайчан таныштык икән соң?.. 2008 нең ахыры иде булса кирәк. Кояш төсендәге сары чәчле, ак итектән, алсу курткадан, гел елмаеп кына торган кыз булып хәтергә уелып калган. Алар шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин (төркемдәше) белән еш кына безнең «Әллүки» түгәрәкләренә кунакка киләләр иде. Бер кич безне тагын да дуслаштырды, берләштерде... Әле дә хәтердә: «Әллүки»дән соң, барыбыз бергә җыелышып, татар җырларын көйләп, Казан урамнарын яңгыратып, көлешә-көлешә өйләргә таралышкан идек.*

*Ә бүген инде урамда яз исен-дәртен күңелләргә салучы 2015 нче елның февраль ае!.. 7 ел эчендә нәрсә генә үзгәрмәгән икән?!.*

*«Дарелфөнүн» басмасын кулга алгач, Динара җитәкчелегендә эшләгән журналистларның тырыш хезмәте күренә, фотосурәтләрне, мәкаләләрне укучыга кызыклы итеп бирүдә Гөлфия Камалиеваның кул эзе, һәр мәкаләне йөрәге-күңеле аша уздырган Роза Асылгәрәеваның милләте өчен янып-көеп йөрүе сизелә. Ә бит һәрбер басманы басма итү дә – олы тырышлык, көч, илһам эше! Һичшиксез, сокланмый мөмкин түгел...*

*2015 нче ел башыннан «Дарелфөнүн» газетасы бераз гына үзгәрешләр кичерде. Әлеге үзгәрешләр бары тик тормышның шатлыклы мизгелләре белән бәйле. Миннекаевлар гаиләсе тиздән кечкенә бала тәрбияләү мәшәкатьләре белән мәшгуль булырга җыена!*

*Шулай итеп, «Дарелфөнүн» басмасы 2015 нче елдан яңа коллектив белән эшли башлый. Тәҗрибәле редколлегиянең тиз арада яңа мөхәррир һәм ике яңа хәбәрчене үз итеп кабул итүе күңелгә рәхәтлек иңдерде. Һәрбер яңа сан белән без иҗади берлектә, элеккеге традицияләрне дәвам итеп, «Дарелфөнүн»гә яңа сулыш өреп, яңа үрләр яуларбыз дип ышанасы килә.*

*Хәерле сәгатьтә, коллегалар!*

*Хәерле сәгатьтә, «Дарелфөнүн»!*

**Эльвира Һадиева.**

Адымнар

# Белем эзләп «Белем.ру»га

**Индира ГАЛИМОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге студенты

Мизгел саен бер адым алга атлаучы бу дөньяда хәрәкәтсез торырга ярамый, шунда ук артка каласың! Яңалыкны кире кагарга да ашыкмагыз – һәрнәрсәдән файда таба белергә кирәк. Кыскасы, көндәлек тормышның бер элементына әверелә барган Интернет киңлекләрен әкерен-әкерен генә татар теле дә яулый бара... Бүген без ЖЧҖ «Белем.ру» оешмасы директоры Гатауллин Раил Мәүлет улы белән татар теленең он-лайн хәле турында сөйләшербез.



**– Раил Мәүлетович, татар порталы проекты нәрсәдән башланып китте?**

- Эшне 2005 нче елда башлап җибәрдек. Иң элек ул гади бер татарча форум буларак оешты. Ул елларда татарча форумнар аз иде. Тора-бара укытучылар ишетеп алды, кызыксынып киттеләр. Ләкин бер урында гына торырга ярамый. 2008 нче елда форум портал буларак формалашты, беррәттән «Мирас» китапханәсе, татар сайтлары каталогы, ресурслар базасы, яңалыклар бүлеге һ.б. проектлар үсеп чыкты.

Бүгенге көнгә күз салсак, проектның формасы шактый гына үзгәрде, ләкин эчтәлеге шул ук – татар мәгарифен үстерү, татар телен яңа чиксез киңлекләргә чыгару. Бу исә, үз чиратында, белемле укытучылар, тиешле методик кулланма, фәнни эшләр һәм татарча файдалы электрон ресурсларсыз мөмкин түгел, минемчә.

**- Чыганакларны, хезмәтләрне кайдан аласыз?**

- Кулланучылар үз фәнни хезмәтләрен портал редакциясенә юллыйлар, биредә аларны белгечләр тикшерә һәм порталның ресурслар базасына урнаштыра. Башка кулланучылар исә әлеге ресурслардан файдалана ала. Бүгенге көндә «Белем.ру» порталы ярдәме һәм, әлбәттә, укытучыларның тырышлыгы белән, яңа методик әсбаплар һәм татар теле дәреслекләре дөнья күрде.

**- Порталда бүгенге көндә ничә кулланучы теркәлгән?**

- Ай саен порталга 10-12 мең кулланучы керә, аның 70-75 проценты – татарстанлылар. Теркәлгән кулланучыларга килгәндә, аларның саны бүген инде 3 меңгә якын. Күпләрне «Белем.ру» оештырган бәйгеләр кызыксындыра.

**- Ә менә конкурслар турында күбрәк сөйләп китә алмассызмы? Студентлар катнаша аламы?**

- Әлбәттә. «Конкурслар» битендә (***belem.ru/konkurslar***) сез барлык бәйгеләребез белән дә таныша аласыз. Мәсәлән, бүгенге көндә «Айның иң яхшы ресурсы» акциясе бара. Порталга килгән фәнни хезмәтләр арасыннан ай саен иң яхшысы сайлап алына, махсус бүләкләр тапшырыла. Ә инде үз сайтын татар телендә эшләткән студентлар өчен дөньякүләм «Белем җәүһәрләре» интернет-проектлар бәйгесе дә бар. Ул Татнетны үстерү фонды, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР Мәдәният министрлыгы һ.б. дәрәҗәле оешмалар һәм иганәчеләр тарафыннан оештырыла. Бәйгенең нигезләмәсе белән бәйгенең рәсми сайтына (http://konkurs.belem.ru) кереп танышырга мөмкин.

**- Менә сез, «Белем.ру» порталы үзгәреш кичерде дигәндә, нәрсәне күз алдында тоттыгыз?**

- 2014/2015 нче уку елы алдыннан «Белем.ру» порталы яңа платформага күчерелде. Мөмкинлекләр киңәйде, дисәм, ялгышмам. Хәзер бездә аудио- һәм видеогалереяләр бар. Анда, укытучылар белән беррәттән, укучылар, ата-аналар кызыклы мультимедиа материаллары таба ала. Шулай ук Татнетны үстерү фонды каршында «Татнет волонтерлары» хәрәкәте үсеп чыкты. Барысын да санап бетерерлек түгел.

**- Хәзер һәр оешма үзен күрсәтергә тырыша бит. Аерылып чыга, бүленә. Сездә андый үзгәрешләр көтелмиме?**

- «Аерылганны аю ашар...», «Бердәмлектә көч» дип юкка гына әйтмиләр. «Белем.ру» оешмасы, Мәгариф һәм мәдәният министрлыклары белән беррәттән, «Сабантуй» һәм «Ялкын» журналлары, «Qazan radiosi» һәм «Тәртип FM» радиолары, башка күп кенә оешмалар һәм проектлар белән хезмәттәшлек итә. Без бердәмлек яклы. Күпме «аерылып» була инде, XXI гасырда исән калу өчен берләшергә кирәк.

**Руфинә Габдрахманова фотосы**

• Яшьлек-яңарыш

# Ә җәй кыштан башлана

Айгөл АБДРАХМАНОВА

Чананы – җәен, арбаны кышын әзерләргә кушалар. Ә бит кемдер, җәй айлары күңелле һәм файдалы узсын өчен, кышкы каникулларын да гыйлемгә корбан итә. Әйе-әйе, сүз кышкы ялларын укып уздыручы студентлар турында. Көлмә, шаярмыйбыз, андыйлар бар!



Александра Живушкина фотолары



Менә, сессия алдыннан гына чаба башлый студентлар, дисеңдер... Сүз бит гади кешеләр турында түгел. Сәләтле кешеләр турында. Кыскасы, әле дә көлемсерәп утырасың икән, димәк, «Сәләт»нең әйдаманнар мәктәбе турында ишетмәгәнсең...

2-6 нчы февраль көннәрендә Теннис академиясендә балаларны яратучы, үз өсләренә җаваплылык алырга курыкмаган 283 булачак әйдаман «Әйдаманнар мәктәбе»нә җыелды. 5 көн дәвам иткән укулар тематик яктан да, башкарылырга тиешле эш ягыннан да төрле һәм кызыклы иде. Беренче ике көн егет-кызларны үзара дуслаштыруга һәм җәйге уку-укыту программасын аңлатуга юнәлтелгән булса, өченче көннән бердәм төркем булып, бер сулыш та эшләү серләрен ача башладылар. Шунысы мөһим: бу көннәрдә «Әйдаманнар мәктәбе» катнашучыларына үзләрен чын әйдаман, остаз итеп хис итү мөмкинлеге бирелде. Алар җәйге аланнарның үзенчәлекләрен, төзелү тарихын өйрәнделәр, балаларны сайлау критерийларын билгеләделәр, һәр аланның эш планын төзеделәр. Соңгы көн исә мөмкин булган каршылыклы ситуацияләрне һәм алардан чыгу юлларын барлау белән узды.

**•Венера Сөләйманова («Әйдаманнар мәктәбе» проекты җитәкчесе):** Әлеге мәктәпнең үз тарихы бар. Заманында бездә, сәләтле әйдаманнарны каян алырга, дигән сорау туды. Уйлашканнан соң, аларны үзебез үк тәрбияләргә тиеш, дигән нәтиҗәгә килдек. Чөнки, сәләтле балалар белән эшләү өчен, махсус тәҗрибә, хәзерлек кирәк. Әйдаман ул – җитәкче. Төрле ситуациядә үзен ничек тотарга тиешлеген белергә мәҗбүр – юкса, сәлкешләр өчен лидер булып кала алмас. Шулай итеп, әйдаманнар мәктәбенә нигез салынды.

Быел «Әйдаманнар мәктәбе» технологик проект буларак яңартылды. Анна Фельдман кебек халыкара дәрәҗәдәге белгечнең безнең белән булуы, уку-укыту программасын җитәкләве дә әлеге проектны бер баскычка күтәрә.

**•Ләйсән Шәйхетдинова (КФУ, Геология һәм нефть-газ технологияләре институты, 1 курс студенты):** Әлеге биш көн миңа яңа идеяләр, үзенчәлекле фикерләр бүләк итте. Элек мин әйдаманлык эшенең тышкы ягын гына белә идем. Хәзер бөтен вакылары белән таныштым. Ләкин җәй көне әйдаман булып эшлисе килү теләге тамчы да кимемәде.

**•Илназ Сибгатуллин (КФУ, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, 3 курс студенты):** Беләсезме, гаиләдә татарча сөйләшеп тә, кеше арасында ана телен кулланмаучылар күп: сөйләшергә оялалар, ялгыш сүзләр кулланудан куркалар – сәбәпләре бихисап. «Сәләт» нең төп максатларыннан берсе – татар телен үстерү. Шуңа да «Әйдаманнар мәктәбе»ндә без әле туган телне кулланырга да өйрәнәбез! Чөнки һәр әйдаман – сәлкешенә үрнәк буласы кеше.

**•Айгөл Закирова («Сәләт-Биләр» аланы директоры, КФУ, Психология һәм белем бирү институты, 5 нче курс студенты):** Мин, киләсе җәйдә директор булып эшлисе килеше буларак, әлеге мәктәпкә килгәндә, әйдаманнар төркеме тупларга өметләнеп килдем. Биш көн эчендә команда җыелды. Без хәтта җәйге аланның юнәлешен, концепциясен билгеләдек, төрле өлкәдә яңалыклар уйлап таптык. Үзем дә камилләшергә өлгердем.

Шуның белән «Әйдаманнар мәктәбе»нең беренче баскычы тәмамланды. Ләкин эшсез утырырга иртәрәк: җәйге аланнарга әзерлек башлана гына, дисәм, тамчы да ялгышмам. Алда күп хезмәт таләп итәчәк дүрт ай. Ләкин Казан федераль университеты студентлары башлаган эшне ярты юлда ташлап калдыра торганнардан түгел. Алар эшчәнлегенең җимешләрен без, һичшиксез, җәй көннәрендә күрербез.

Татар Балы

# Ишәк һәм сакал турында түгел

Энҗе ИБРАҺИМ, Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты студенты

Театрда кызыл төс сорыга алышынды. Яңа спектакльнең төп төсе бу! «Күңелсез» икән дип нәтиҗә чыгарганчы, Камал театрына барып, сәхнә уртасында һавада эленеп торган зу-у-ур соры филгә күз салырга киңәш итәм. Һәм аннан соң гына чуар чапанлы Хуҗага.

Кем-кем, ә мин Хуҗа белән бик яхшы таныш. Икесе белән дә: образ белән дә, башкаручысы белән дә. Университетта биш ел төрек телен өйрәнү дәверендә Хуҗа турында нинди генә хикәят, нинди генә риваять ишетмәдем. Укытучыбыз Мостафа бей дәресен Хуҗа исеме белән башлый, Хуҗа белән бетерә, ә кайчакларда хәтта дәрес буе Хуҗа турында сөйләп чыга иде. Әтиемнең дә кул астында (машинада, өстәлендә) йөрткән иң якын һәм тугъры китабы – таушалыплар беткән кечкенә яшел «Хуҗа Насретдин мажаралары». Ни гаҗәп, татар сәхнәсенә дә бу әсәр инде җиденче (!) тапкыр менә икән. Татар Театры тарихы китабын ачып, махсус санап чыктым... Сәхнәдә куелу саны буенча, «Хуҗа»ны бары «Галиябану» белән «Банкрот» кына уза. Димәк, бу – төп өчлеккә кергән, халык күңеленең иң-иң түрендә булган әсәр. Юкка түгел. Режиссер ялгышырга мөмкин, актер ялгышырга мөмкин, тик халык... беркайчан да! Ул үзенә кирәген гел белә һәм «тартып китерә». Димәк, хәзер дә менә халык үз «Хуҗа»сына сусаган булган.

Узган премьерадан соң, нәкъ менә «Хуҗа» җитмәгәнлеге бик яхшы аңлашылды! Репертуарга, театрга, халык күңеленә.

Җиде саны да юкка гына тылсымлы дип йөртелми икән, бу җиденче куелыш иң отышлысы, миңа калса. Гәрчә, алдагы алтысын карамасам да. Абсурд яңгырыймы? Ә мин барыбер шикләнмим! Чөнки һәр чорның үз «Хуҗа»сы. Минем күңелемә тиң килгәнен Фәрит Бикчәнтәев кабызды, даһиларча оста итеп, Фәнис Җиһанша башкарды. Бу рольне нечкә итеп тоеп кына уйнап буладыр. Импровизация, кинәтлек, сүз батырлыгы, җан көрлеге,тапкырлык, галәми тынычлык... Барысы да граммы грамма кушылган. Афәрин, Фәнис абый! Җиһангир кебек бертуктамый «каррале, кар-р-рале» дип тамаша кылдык. Димәк, чын мәгънәсендә сокландык. Хуҗа халыкны чишендерә, оятка калдыра, тәхеттән төртеп төшерә, көлдерә, елата, гашыйк итә... һәм уйландыра. Уйландырдыгыз! Хуҗа каршыбызда көзге тотып тора. Без бактык һәм курыктык! Димәк... Булдырдыгыз!

Режиссер Фәрит Бикчәнтәев, Нәкый Исәнбәт һәм Саадалла Ваннусның пьесаларын бергә кушып, зур яңалык тудырган, бу, һичшиксез, постмодернизм. Димәк, һәркем үзенекен, үз дигәнен, күңеленә якынын, кирәген табачак.

Халкымның җанына сеңгән зирәклеккә тагын бер кат гашыйк булып кайттым. Минем дә хәзер кайбер кунакларга, тагарагы белән су чыгарып, Баба шулпасы ашатасым килә, минем дә шулай, импровизациягә буйсынып, җор телләнеп, үткен итеп сөйләшәсе, шаккаттырасы, кайберләренең хөлләләрен, чапаннарын киеп, күз кысасым килә башлады.

Бу тилелек, гадилек катнаш зирәклектә күңел моңы бар. Сакаллы моң. Минем дә үтә күренмәле ишәгем бар хәзер, сакаллы моңым, моңлы сакалым бар. Ә сез театрдан ниләр алып кайттыгыз?



✦ Солдан уңга: Фәнис Җиһанша һәм Фәрит Бикчәнтәев. Автор фотосы.

DARELFӨNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: Э.Р.Һадиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълумати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Басуырга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.